РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ**
**ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
**ЧИСТАЙ**
**ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**24.05.2023 ел** **Чистай шәһәре** **№22/4**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Федераль һәм республика законнары үзгәрүгә бәйле рәвештә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, “Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында”гы 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставының 92 - 94 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2014 елның 14 февралендәге 28/6 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына (Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 21.05.2015 ел №40/2, 23.12.2015 ел №3/7, 15.12.2016 ел №10/6, 31.08.2017ел №17/7, 21.03.2018ел №23/2, 24.10.2018ел 28/6, 04.07.2019ел №36/1, 13.05.2020ел №46/6, 28.04.2021ел №7/5, 12.05.2022ел №14/3 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 13 һәм 12 статьяларда «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 19 статьяда:

1.2.1. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. гавами тыңлаулар үткәрү вакытын һәм аларны үткәрү урынын күрсәтеп, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында системасында урнаштырылырга тиеш.»;

1.2.2. 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Халык алдында тыңлаулар уздыру һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты турындагы мәгълүмат басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән башлап, Җирлек халкы Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең

(функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты яисә проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрергә хокуклы. Җирлек башлыгы керә торган тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерә.»;

1.2.3. 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре басылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, шул исәптән Чистай муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»;

1.3. 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирлек Советы депутаты җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән җирлек Советының оештырылган бар утырышларында булмаган очракта, җирлек Советы карары белән җирлек Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»»;

1.4. VII бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. Текст буенча «Татарстан Республикасы Башлыгы» сүзләрен тиешле килешләрдә «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис) сүзләре» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәве алганнан соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравога йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов